


# Рахманова Рәзилә Рәдиф кызы

# 29.05.1995.

**Татарстан Республикасы Биектау районы Айбаш урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы**
**Адрес: 422726, ТР, Биектау районы, Каракүл авылы, Зур урам, 1нче йорт**

**Яраткан шөгылем:бәйләү, чигү, ашарга пешерү, китап уку.**
**«Вперед – в прошлое 2012» бәйгесендә “Дәү әни белән дәү этигә -кунакка” номинациясендә катнашам. Темам:” Их, татар ашлары...”. Эшемдә безнең якларда кош телен ничек пешерүләре турында яздым.**

# Каракүлем-гомер бишегем



Гүзәл табигатьле туган авылым-
**Каракүлем**-гомер бишегем.
Әйтеп тору кирәк булыр микән,
Туган җирдә яшәү ничеген.

Дөньякүләм мәшһүр яңартулары, шарлавыклары,упкын тарлавыклары булмаса да, Татарстан табигатенең дә котелмәгән могҗизалары,күңелне сөендерә яки кинәт сискәндерә торган күренешләре юк түгел.

Туган як, туган җир, туган авыл... Нинди тирән мәгънә ята бу сүзләрдә! Сиңа бик якын да, бик кадерле дә бит алар. Чөнки монда синең ата-бабаңның нигез туфрагы. Алар шунда беренче тапкыр дөньяга аваз салганнар. Син дә, димәк, шушы як, шушы җир кешесе, шушы туфрак баласы. Шуңа күрә синең өчен ул бик тә изге һәм кадерле.

Һәрбер кеше туган ягы, туган авылы, ыру-заты, нәселе турында уйлана, аның тарихы белән кызыксына. Әгәр чит җирләргә китеп барса, аны сагынып кайта. Чөнки туган як беркайчан да истән чыкмый, һәр кешене туган якның урманнары, һавасы, сулары, чишмәләре, кешеләре сагындыра. Ул туган теленә, моңына сусый.

Минем туган авылым- Каракүл. Каракул-район үзәгеннән 48 чакрымда,җирле үзидарә советыннан 3 чакрым ераклыкта урнашкан кечерәк кенә бер авыл.

Аның моңа кадәр таралып бетмәве бик гаҗәп, чөнки ул атама буларак берни аңлатмый торган ”Урал” исемле колхоз атлы авылны, ягъни Айбаш, Апсабаш, Зур Көек, Каракүл, Кодаш, Яңавыл авылларын берләштерә. Бу очракта да җирле үзидарә советы һәм колхоз үзәге булган Айбаш авылы үсә һәм зурая, ә шушы колхозның бүлекчәләре булып калган башка авыллар кечерәя, искерә, картая.

Элек авыл урынында зур урман үскән. Авыл янында Ышна атамасы билгеләнгән.

“Каракүл” атамасы Каракүл исемле гидронимга мөнәсәбәтле. Ә ул үзе ни өчен шулай аталган соң?

Бу атаманың барлыкка килүе җирнең геоморфологик төзелеше белән бәйләнешле. Татарстанның кайбер районнарында суда тиз эрүчән карст токымнары очрый. Бу токымнар эрү нәтиҗәсендә Упкын күлләр дә ясала. Төбендә мондый токым булган күлләрнең суы үзенә бер кара-кучкыл төс алып тора.




Дөбьяз районы җирләре геоморфологик яктан шактый үзенчәлекле. Бу районның кайбер төбәкләрендә, аерым алганда Ашыт бассейны, карст токымнарына бик бай доломит- известьташтан тора. Тиз эри торган бу катлам җир өстенә якын урнашкан. Карст токымнары эрү нәтиҗәсендә Ашыт елгасы бассейнында җир асты сулары күп.

Каракүлнең дә суы каралып тора. Ләкин еллар үткән саен, ул саегая бара.

Хәзер Чаллыда күлләрне чистартып, төбендәге ләмне алып, колхозларга сата торган кече предприятие оешкан. Каракүлнең төбендәге ләмен чистартып җибәрсәң, ул тирәнәер, ләме басу уңышын арттырыр иде.

Каракүлнең тирә-юне элек камышлы һәм җикәнле булган. Хәзер исә аның матурлыгы бетеп бара.



Авылда 45дән артык хуҗалык барлыгын, халыкның игенчелек белән дә шөгыльләнүен, эшчән һәм булдыклы булуын да әйтеп китәргә кирәк. Өйләргә газ ягыла, күп йортларга телефон кертелгән, юлларга асфальт түшәлгән. Авылда мәчет бар. Халык зиратны карап, тәрбияләп тора, ялгыз әби-бабайларны онытмый. Яшьләр авылда кала. Йортлар матур һәм яңа. Авыл тагып да үсүгә, матурлыкка юл тота. Авылның якын-тирәсендә зур болыннар юк. Урманнарга килгәндә, алары да бик якын түгел һәм барысы да авылдан көньяктарак урнашкан. Алардан соң да урманнарның иге-чиге юк. Авыл халкы печәнен дә, утынын да, җиләк-чикләвеген дә шул урман-болыннардан җыя.

Этник составына килгәндә, авылда татарлар гына яши. Аларның күп өлеше колхозчылар - механизаторлар, терлекчеләр, төрле эш башкаручылар да күп. Соңгы елларда авылда фермер хуҗалыклары барлыкка килде. Халыкның бер өлеше аларда эшли. Шулай ук, мәктәп укытучылары, авыл советы һ.б. оешма хезмәткәрләре халыкның шактый зур өлешен тәшкил итә.




Халыкның теле Казан арты сөйләменә керә һәм анда й - җ күчеше аеруча көчле. Мәсәлән, "ерак" диясе урынга "җырак", "юк" урынына "җук" диләр. "Бара идем" урынына "бара ием", "кайта идем" урынына "кайта ием" диләр, "пычрак" урынына "былчырак" дип сөйлиләр. Авылда борынгы йолалар сакланмаган

диярлек. Ләкин, коры килгән җәйләрдә картларның басуга чыгып намаз укыганы, әлбә пешереп су сибешү кебекләре була иде. Хәтеремдә - без бәләкәй чакларда яшьләр һәм балалар бергә җыелып, чиләкләргә су салып, кем туры килсә шуны - яшен дә, картын да су белән коендыра торган идек. Ә суның нинди генә юк: ул чишмәдән дә, коедан да, һәр йортның каршында торган кисмәктән дә алына торган иде.

Соңгы елларда халкыбызның борынгы бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре яңадан кайта башлады. Шундыйларга: каз өмәсе, Нәүрүз, Гает бәйрәме керә.

Каракүл халкы элек суны коелардан, чишмәләрдән алган. Хәзер күбрәк колонкалардан ала яки суүткәргеч торба аша өйгә кертә.

1552 елда Казан ханлыгы яулап алынган вакытларда Казан гына түгел, Казан Арты да сугыш мәйданына әйләнә. 50 меңгә якын халык дошманга каршылык күрсәтүдә турыдан-туры катнаша. Биектауның үзендә дә ныгытма корыла. Татарлар шуннан Казанга һөҗүм итеп торалар. Ләкин, бер айдан артыкка сузылган аяусыз сугыштан соң, 2 октябрь көнне Казан яулап алына. Шуннан соң да әле 1557 елга кадәр "Казан сугышы" дәвам итә, татар халкы басып алучыларга каршы көрәш алып бара. Ул рәхимсез бастырыла, рус гаскәре үткән татар авыллары җир белән тигезләнә, кырлар таптала. Казанга 40 километрдан якынрак булган татар авыллары җирләреннән куыла. Колониаль сугыш нәтиҗәсендә күп авыллар бушап кала, җәннәт дип аталган Казан Арты Россия империясенең икътисади, социаль һәм милли басымы астында хәерче бер төбәккә әверелә. Мәсәлән, Арча даругасында гына да (Казан ханлыгы чорында билгеле бер юнәлештәге бистә һәм авылларны берләштергән төбәкне - административ берәмлекне - даруга дип атаганнар) XVII гасырда биредә халкы качкан өч буш җир (русча: пустошь) була. Соңрак шундый урыннарда яңадан авыллар барлыкка килә.

Тормыш бераз яхшыра гына башлаганда, 1941 елны Бөек Ватан сугышы башлана. Каракүл авылының бик күп ирләре сугышка алына. Кайбер хатын-кызлар да сугышка китә. Кыр эшләре дә тол хатыннарга, яшүсмер малайларга кала. Алар сугышка киткән әтиләрен, ирләрен, улларын алыштыралар, авыр шартларда җиңүгә үз өлешләрен кертәләр. Авылдагы юньлерәк атлар фронтка алына. Сукага үгез һәм сыерлар җигәргә туры килә. Җирләр әйбәт эшкәртелмәгәч, иген дә уңмый. Ашлама юк, кырга тирес чыгарылмый. Авыл кешеләре лом, китмән, көрәкләр күтәреп тимер юл төзелешендә эшлиләр, дошман килергә мөмкин булган урыннарда окоп һәм ныгытмалар казыйлар, урман кисәләр, оек-бияләйләр бәйләп, төрле күчтәнәчләр салып фронтка посылкалар җибәрәләр.

Сугыш дәвамында авылга бер-бер артлы кайгы хатлары килеп тора, кайберәүләрне госпитальдән авылга, савыгырга җибәрәләр дә, бераздан тагын сугышка алып китәләр. Күпләр бөтенләй эшкә яраксыз, кулсыз-аяксыз, күзсез булып кайталар.

Сугышта Каракүл авылыннан киткән 300гә якын кеше һәлак була. Алар истәлегенә авыл уртасында һәйкәл куелган.

Каракүл авылы тау-калкулыклар арасына урнашкан (Кашлак, Һаҗәрләр, Үтиләр, Зират, Кибет, Асия, Кара Митаклар, Гобәй Тәскирәләре тавы, Әмбәт күле тавы, Мыслы тавы, Ташкан тавы, Айбаш тавы)

Чишмә-чыганакларга, урманнарга, сазлыкларга һәм башка географик берәмлекләргә халык үзенчәлекле исемнәр биргән. Якын тирәдә Кодаш,

Кәҗүнни, Каракүл, Сәлим урманы, бар. Шулай ук Артыш сазы, Көек юлы сазы, Шәрифә чишмәсе, Сәкил тау асты, Тимерче чокыры, Гайшәләр асты исемен йөрткән географик берәмлек атамалары да бар.

Каракүл халкы урам исемнәрен үзенчә атый: Олы урам, Яңа урам, Мәчет урамы, Җәрмәк урамы. Тыкрык исемнәре дә бар: Вафалар тыкрыгы, Гыйлаҗлар тыкрыгы, Гайҗаннар(Газизҗаннар) тыкрыгы.

Каракүлдә кибет, клуб эшли. Быел сентябрь башында башлангыч мәктәпне яптылар.



Авылыбызның яңа мәчете. Ул 2005 нче елда төзелде. Менә шундый минем туган авылым-Каракүлем.